# КАРАР

**2019 елның 3 декабре** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлегенең Арпаяз авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәсе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 28 ноябрендә һәм 2019 елның 30 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар, I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлегенең Арпаяз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2020 елда үзара салымны 1500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Арпаяз авылы зиратын киртәләп алу өчен материал сатып алу;
- Әсән-Елга авылы зираты өчен коймаларын кору, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Арпаяз авылының Яр буе урамына юл билгеләре сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү;
- Арпаяз авылы юлларын кардан чистарту;
- Арпаяз авылында артезиан скважинасы өчен насослар сатып алу;
- Арпаяз авылына энергия саклагыч урам утлары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, килешүе буенча түләү;
- Арпаяз авылында спорт инвентарьлары сатып алу;
- Арпаяз авылының Яр буе урамында юлга вак таш җәю; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Арпаяз авылына вак таш сатып алу һәм ташу;
-Арпаяз авылының Береговая урамында янгын гидрантлары һәм кое сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 129 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 72.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 72 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлеге Арпаяз авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәләне: «Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар, I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлегенең Арпаяз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2020 елда үзара салымны 1500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Арпаяз авылы зиратын киртәләп алу өчен материал сатып алу;
- Әсән-Елга авылы зираты өчен коймаларын кору, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Арпаяз авылының Яр буе урамына юл билгеләре сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү;
- Арпаяз авылы юлларын кардан чистарту;
- Арпаяз авылында артезиан скважинасы өчен насослар сатып алу;
- Арпаяз авылына энергия саклагыч урам утлары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, килешүе буенча түләү;
- Арпаяз авылында спорт инвентарьлары сатып алу;
- Арпаяз авылының Яр буе урамында юлга вак таш җәю; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Арпаяз авылына вак таш сатып алу һәм ташу;
-Арпаяз авылының Береговая урамында янгын гидрантлары һәм кое сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру?

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында

www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Пычак авыл җирлеге башлыгы Г.Ш. Нәфыйков